*Инсафутдинова М. Т. (РИИ, Казань)*

# XVIII ЙӨЗ ИСТӘЛЕГЕ “ФӘҮЗЕН-НӘҖӘТ” ПОЭМАСЫНЫҢ СТРУКТУРАСЫ

Татар әдәбиятының XVIII йөз дәвере аз өйрәнелгән дәверләрнең берсе булып кала бирә. Чыганаклар саны аз булмаса да, аларны текстологик өйрәнү өлкәсе пассив халәттә. Кызганычка каршы, әдәбиятыбызның кабатланмас мөһим урынын алып торган “Фәүзен-нәҗәт” әлегә кадәр өйрәнелмәгән иде. Аны хәтта текстологик яктан гына да тикшереп караучылар аз булды. Моны XVIII йөз татар әдәбияты тарихының ак табы дип әйтергә мөмкин. Әсәр турында өзек-өзек фикерләрдән башка искә алып үтәрлек мәгълүмат юк дәрәҗәдә. Аның басылу тарихы һәм кулъязмалары хакында да әйтүче табылмады.

Равил Әмирхан “Дәреслекләребезнең тирән тамыры” мәкаләсендә “Фәүзен-нәҗәт” ядкярен мәдрәсәләрдә киң таралган популяр уку китаплары исәбеннән санап китә. Шулар арасыннан Пиргули (Мөхәммәд Пиргули, 1538 – 1578), Устуани (Мөхәммәт Устуани, 1607 – 1662), “Бәдәвам”, “Рисаләи Газизә”, “Фәзаил-әшшөһүр”, “Мөһиммәтел-мөслимин”, “Сөбателгаҗизин”, “Мөхәммәдия”, “Гыйбрәтнамә”, “Бакырган” һ.б.[1]

Шундый күренекле мәдәни ядкәребез, бик күп кулъязма нөсхәләре билгеле булуга да карамастан, әле һаман укучыларга тәкъдим ителмәгән хәлдә кала килү – татар әдәбияты өчен бик тә аянычлы. Поэманы фәнни-филологик яссылыкта өйрәнеп, аны киң катлау җәмәгатьчелегенә тәкъдим итү – әдәбиятыбызның

١ ٣ Там же

аерым мөһим үзенчәлекләрен күрергә ярдәм итәр иде. Бүгенге көндә дә актуаль бакый мәсьәләләрне ачып торучы әдәби әсәр кушылса, әлбәттә, XVIII йөз татар әдәбиятына байлык өстәр иде. Шундый асыл тамырлы, ачык, тулы әсәр әдәбиятыбызны бары тик ныгыта, үстерүне тәэмин итә.

"Фәүзен-нәҗәт" - татар халкын иманлы, белемгә омтылучан, нык ихтиярлы, мәдәни, сәламәт яңа дәвер кешесе итеп тәрбияләүгә зур программа була. Әсәрнең структурасы логик эзлекле, дидактик яктан максатчан уйланып бирелгән. Без поэманы шартлы рәвештә бүлекләргә аерып күзәтербез һәм һәр бүлекнең үзенчәлеген күрү нияте белән тукталып китәрбез. XVIII гасыр татар поэзиясенең хәзинәләреннән уртак якларын күрсәтербез.

Димәк, "Фәүзен-нәҗәт"нең түбәндәге бүлекләрен аерып алырга мөмкин:

1. Кереш бүлек. Аллаһы Тәгаләне, пәйгамбәрләрне олылау, мактау.

2. Авторның әсәрен тудырырга этәргән мәсьәләләр. Шәригать кануннарын бәян итү.

3. Намазга әзерлек этабы – тәһарәт.

4. Намаз турында белешмә мәгълүматлар.

5. Мөселман кешенең әхлагыгын камилләштерү:

Ир-хатын мөнәсәбәтләрен чагылдыручы хикәяләр.

Тормыш-көнкүрештә очрый торган этикет мәсьәләләрен тасвирлый торган хикәяләр.

Күңел сафлыгына ирешү өчен файдалы үгет-нәсихәт (дуслык, бурыч, хирыслык, көнчелек, гайбәт һ.б.)

6. Имамның сөйли торган фәтвәләре.

7. Мөселман шәхесен камилләштерүгә ирештерә торган иллюстратив сюжетлы хикәяләр.

Кереш бүлек. Аллаһы Тәгаләне, пәйгамбәрләрне олылау, мактау.

Хакыйкый мөселманның тормышын Аллаһының җитәкчелегеннән башка күз алдына китерергә дә мөмкин түгел. Дин – фани дөньядагы иң изге сыйфатларны сугаручы илаһи бер чишмә. Диннең максаты, функциясе – аерым бер кешенең яки аерым бер гаиләнең, яисә җәмгыятьнең генә тормышын төзәтер өчен, ә иң мөһиме, барлык халыкларның юлын яктыртучы нур итеп, аларны караңгылыктан яктылыкка чыгару өчен хезмәт итү.

Хәдиснең берсендә "Дин – нәсихәттер" диелә. "Нәсихәт" сүзе берничә мәгънәне үз эченә ала. Берәүгә дустанә мөнәсәбәттә яхшылык теләп нәсихәт кылу мөмкин. Ә дини яссылыкта - Аллаһ өчен нәсихәт, ягъни Аллаһка иман

китерү, хөрмәт итү, олылау, әмерләрен, таләпләрен үтәү, тыйганнарыннан тыелу, нигъмәтләренә шөкер итү. Болар барысы да ахыр чиктә бәндәнең үзенә кайтып үз файдасы өчен генә була.

“Фәүзен-нәҗәт” китабы иҗат ителгән дәвердә күпчелек язучылар ислам идеологиясеннән чыгып эш иткәннәр. Мөселманнарның изге китабы “Коръән” башламы да Алланы олылауга, мактауга багышланган. Галәмне, дүрт стихияне, фәрештәләрне һ.б. яратучы кодрәт илаһы дип бирелә.

Бисмиллаһир-рахманирахим.

Сәнә эл-халикъ арыз вә самәвәт,

Китерде кяф-нундин күб галәмәт.

Йаратты миһер вә маһ вә ни фәләкне,

Кәвәкәб берлә саны уйк мәләкне.

Йаратты аб Хакъ атәш бад,

Бу түртдин орды ул һәр җисмә бинйад.

Поэтик контекстта традицион дини тематикага багышлап языла. Алла (кайчак Мөхәммәд пәйгамбәр дә), мәсәлән, гаделлек, хаклык, сафлык, шәфкать юмартлык, абсолют идеал рәвешендә бирелә.

Билгеле инде, Урта гасыр традицион тематикасы дини яссылыкта бара. Бу дәвер әсәрләренең тематикасы бердәм төсмердә ачыла. Нигездә, үзәк проблема – кешенең Аллага мөнәсәбәтен яктыртуга төп урын бирелә. Шәхеснең рухи халәте дә, эш-гамәлләре дә шушы мөнәсәбәткә нисбәтән гәүдәләнә. “Фәүзен-нәҗәт” – ягъни “бәлаләрдән котылу юлы” Аллага якынаюдан икәне ачык аңлашылып тора. Димәк, бәхеткә ирешү үз күңелеңне саф мөселманча тотудан гыйбарәт.

Әхмәт Ясәви һәм Сөләйман Бакырганиларның дәвамчысы Суфи Аллаһиярның “Сөбателгаҗизин” әсәре дә структур яктан анализлаганда Аллаһыга мәдхия темасы белән башлый. Аның фикеренчә, Аллаһы Тәгалә кебек гүзәллектә, гаделлектә өстен зат юк.

Рәхимле һәм мәрхәмәтле Аллаһы Тәгалә исеме белән (башладым)!

Сәна лилхалики габрәиәхлак,

Яратты катрәдин гәвәһире пакь.

Сәмәват өвене тотты моталлап,

Җәһанәс хөкмене күрсәтте мотлап.

Кылап габрә мәдарин зәммәе хут,

Бәни адәмә кыйсме итте кот.[1]

1 Баязитов Г. Янэ тел мэсьэлесе(И снова к языково-

Шулай итеп, һәр ике әсәр дә Аллаһы Тәгаләгә дан җырлау белән башланып китә һәм аның кодрәтләре бәян ителә, изгеләр, пәйгамбәрләр ягында булуын белдерелә. Әсәрнең беренче өч-дүрт бәетен башка шагыйрьләр үз әсәрләрен башлап җибәргәндә дә файдаланыла торган булганнар. Мәсәлән, Утыз Имәнинең "Горбәтнамә" поэмасында чагыштырып карарга мөмкин:

1.Сәна лилхаликы габрә вә әфляк,

Яратты катрәдин гәвәһире пакь.

2.Сәмәват ивене тотты мөгалләкъ,

Җиһанә хөкмене күрсәтте Мотлак.

3.Кылт габре мәдарын зәммә-и хут,

Бәни адәмгә кыйсем итәр кот.[1]

Күргәнебезчә, охшашлык ап-ачык. Хәтта поэтик алымнарында, сүзләрендә дә охшашлык сизелә.

Диде мин нардин, ул аб көлдин.

Аллаһы Тәгаләнең моңа исемне Иблис дип куя һәм аңа төрле дәлилләр китерә.

Кяһи ташдин чыкарыр ут белә су,

Бу эшне кем кыйлыр, кыйлмас мәгәр һу.

Кяһине дин чыкарыр төрлүк аһәң,

Акызырга шөкер хуш тәгам, хуш рәң.

Чыкарыр нишдин ул нуш дару,

Чыкарыр нафә мөшек ул заһу.

Ни кадәргә кодрәтле Ходадыр,

Бу эшдин бәндәнең гаклы җөдадыр.

Җирдән төрле хуш исле искиткеч гөлләр үстереп барлыкка китерүен автор сәнгатьләрнең сәнгате дип атый. Берәүнең башына мәхәббәт хисен төшерде, икенчегә тәхеттә утырырга боерды, берәүне гөлстанда яшәр өчен, ә икенчене корбан итеп яраткан һ.б. Гомумән, бар нәрсә дә Аллаһ теләп, аның кодрәте белән эшләнә. Кешенең акылына сыймаслык гамәлләр кыла алучы Аллаһның кодрәтендә шикләнергә ярамый, дигән фикер уздыра автор.

Имәс һәр җенес бер беригә манәнд,

Гаҗәб кодрәтле надыйр Ходавәнд.

Үзен мөселман дип санаган кеше түбәндәгеләргә ышанырга тиеш:

1.Аллаһның барлыгына һәм берлегенә.

2. Фәрештәләргә.

3. Китапларга.

му вопросу)//Нур . – 1906. – 19 окт.

1 Баязитов Г. Әдәбият тәрбиясе (Литературное воспитание)// Нур. – 1906. – 26 июн.

4. Пәйгамбәрләргә.

5. Заман ахырына.

6. Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһ Тәгаләдән булуга.

7. Үлгәннән соң терелүгә.

Әлеге җиде хакыйкатькә бернинди исбатлау сорамыйча, шик белдермичә, ихластан ышанырга тиеш. Мөхәммәд пәйгамбәр үзенә пәйгамбәрлек килгән әүвәлге унике елында кешеләргә шушыларны аңлатты. Боларга инанмаган кешеләрнең ихтыяр көчләре булмый, Аллаһ кушканны үти алмыйлар.

Суфи Аллаһиярның “Собател-гаҗизин” поэмасының әүвәлге хикәяләренең берсендә мөселманны иман юлыннан барган очракта гына яшәвенең яме булыр дип фаразлый:

Мөселманлык юлында будыр иман,

Моны белмәс кеше хәле бик яман.

Кулланылган әдәбият исемлеге:

1. Аллаһияр Суфи. Собател-гаҗизин. – Казан: Татарстан республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002.

2. Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: ТКН, 2000.

3. Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1997. – 189 б.

4. Габдерәхим Утыз Имәни. Шигырьләр, поэмалар. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1986.

5. Миңнегулов Х. Шәрекъ һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар. (Поэтика һәм әдәби бәйләнеш мәсьәләләре). – Казан: КУН, 1988.

6. Рухи тәрбия (басмага әзерләүче Н.Ибраһим). – Казан: Россия Ислам университеты нәшр., 2003.

7. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. – Казан: ТКН, 1986. – Т.I.